**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Яңасала авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның 15 ноябре** **№ 105**

**Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хәрби исәпкә алу буенча белгечләргә хезмәт хакы түләү турындагы Нигезләмәне раслау турында**

2006 елның 29 апрелендәге “Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр турында”гы 258 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Карары, 2003 елның 6 октябрендәге 131 –ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 53 маддәсе, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 144 маддәсе нигезендә, Россия Федерациясе оборона Министрлыгының 2009 елның 25 апрелендәге 315/2/203 номерлы хаты һәм хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы белгечләргә хезмәт хакы түләү турындагы Нигезләмәне расларга.
2. Әлеге Карар 2018 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында басылып чыгарга тиеш.
3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яңасала авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Яңасала авыл җирлеге башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Яңасала авыл җирлеге**
**Советы Рәисе** **И.Х. Шиһабиев**

2018 елның15 ноябрендәге
Кама Тамагы муниципаль
районы Яңасала авыл
җирлеге Советының
105 номерлы Карарына
1 номерлы кушымта

**Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хәрби исәпкә алу буенча белгечләргә хезмәт хакы түләү турындагы Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә 2006 елның 29 апрелендәге “Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр турында”гы  Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 258 номерлы Карары, 2003 елның 6 октябрендәге 131 –ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 53 маддәсе нигезендә эшләнде.

2. Әлеге Нигезләмә хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы җирлекнең хәрби-исәпкә алу хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибен җайга сала.

3. Әлеге Нигезләмә хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә хәрби исәпкә алу буенча белгечнең һәм беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хезмәт хакын билгеләгәндә кулланыла.

4. Хәрби-исәпкә алу хезмәткәренең хезмәткә түләү фонды, җирлеккә тапшырыла торган федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләр күләменнән чыгып, календарь елга төзелә.

5. Өстәмә түләүләр күләме хезмәт өчен түләүгә бүлеп бирелгән акчалар чикләрендә билгеләнә.

## II. Хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары

1. Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы белгечләрнең хезмәте өчен түләү әлеге Нигезләмә нигезендә башкарыла һәм айлык вазыйфаи окладтан (алга таба - вазыйфаи оклад), компенсация түләүләреннән һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрдән тора.

2. Ике эштә эшләү (совместительство) буенча эшләүче хәрби исәп хезмәткәрләре өчен сәгать атнасы хәрби исәптә торучы гражданнар санына турыдан-туры пропорциональ рәвештә билгеләнә.

3. 2008 елның 5 августындагы “Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 583 номерлы Карарын гамәлгә ашыру чаралары турында”гы Россия Федерациясе оборона Министрының 2014 елның 23 апрелендәге 255 номерлы боерыгы нигезендә хәрби-исәпкә алу хезмәткәренең вазыйфаи оклады күләме, инспектор окладына тиңләштерелгән кертемнең күләме.

| Вазыйфаи оклад | күләме, сум. |
|---|---|
| Исәпкә алу һәм броньлау буенча инспектор | 6 552,00 |

4. Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 282,284,285 маддәләренә туры китереп, уртак эшчәнлек буенча вазыйфаларны башкаручы хәрби-исәпкә алу хезмәткәренең вазыйфаи окладының максималь күләме азат ителгән хәрби-исәпкә алу хезмәткәренең хезмәт окладының 50% ыннан артмаска тиеш. Уртак эшчәнлек буенча вазыйфаларны башкаручы хәрби исәптә торучы гражданнар санын исәпкә алып, хәрби-исәпкә алу хезмәткәренә түбәндәге вазыйфаи окладлар билгеләнә:

– хәрби исәптә 400 граждан булганда - азат ителгән хәрби-исәпкә алу хезмәткәренең хезмәт окладыннан 40%.

5. Хезмәткәргә кызыксындыру характерындагы түбәндәге түләүләр башкарыла:

а) Россия Федерациясе оборона Министрлыгының 2014 елның 23 апрелендәге 255 номерлы боерыгы нигезендә билгеләнгән тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү

Хезмәткәрләргә тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү түбәндәге күләмнәрдә әлеге өстәмә түләү алу хокукын бирә торган эш стажына карап дифференциацияләнгән рәвештә башкарыла:

| Эш стажы | күләме (вазыйфаи окладка процентларда) |
|---|---|
| 1 елдан 2 елга кадәр | 5 |
| 2 яшьтән 3 яшькә кадәр | 10 |
| 3 елдан 5 елга кадәр | 15 |
| 5 елдан артык | 20 |

Тиешле елларны эшләгән өчен айлык өстәмә түләү билгеләү хокукын бирә торган эш стажын исәпләгәндә исәпкә алына торган чорлар календарь хисапында билгеләнә һәм суммалаштырыла. Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү алу хокукын бирә торган эш (хезмәт) стажын билгеләү өчен төп документ булып хезмәт кенәгәсе (хәрби билет) тора. Эш (хезмәт) стажын раслап, хезмәткәр тарафыннан шулай ук тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү алу хокукын бирә торган эш (хезмәт) стажы булуны

раслаучы башка документлар да тәкъдим ителергә мөмкин. Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә билгеләнә һәм әлеге өстәмә түләү күләмен билгеләү яки арттыру хокукы барлыкка килгән вакыттан түләнә.

Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә күләмен вакытында яңадан карау өчен җаваплылык кадрлар эше өчен җаваплы хезмәткәргә йөкләнә. Тиешле елларны эшләгән өчен айлык өстәмә билгеләү тиешле хокукый акт белән рәсмиләштерелә.

б) вазыйфаи бурычларны намуслы башкарган өчен елына 2 вазыйфаи окладка кадәр акчалата бүләк;

в) эш нәтиҗәләре буенча вазыйфаи окладның 25 проценты күләмендә айлык премия.

Айлык премия хезмәткәрләргә сыйфатлы, оператив эшләр башкарган өчен түләнә.

г) Федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка хокукый актлары белән каралган башка түләүләр.

6. Компенсация түләүләр үзенчәлекле климат шартлары булган җирлекләрдә эшләгән өчен түләүләрне үз эченә ала. 2014 елның 23 апрелендәге Россия Федерациясе оборона Министрлыгының 255 боерыгы нигезендә, хәрби-исәпкә алу хезмәткәренең Татарстан Республикасы өчен хезмәт хакына район коэффициенты күләме 1,15 тәшкил итә.

## III. Хәрби исәпкә алу буенча белгечкә ял (отпуск)

Хәрби исәпкә алу буенча белгечкә ел саен 28 календарь көн дәвам иткән түләүле ял бирелә. Ике эштә эшләүче белгечләр өчен еллык түләүле ял төп эшчәнлек буенча ял белән бер үк вакытта бирелә.